
**ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Ленина, 37 «А»
тел. (факс): 8(84348) 2-25-47, 8(84348) 2-27-67



**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЛЕКҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 37 "А"
тел. (факс): 8(84348) 2-25-47, 8(84348) 2-27-67

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

2025 елның «30» сентябрь № 357

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 17 февралендәге 96 номерлы боерыгы белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

1. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары, 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боерык бирә:

- 2.8.2.1 пунктының 16 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«16) бакчачылык яки бакчачылык коммерцияле булмаган ширкәтенә җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге мәйданы

әлеге Кодексның 39.10 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән чик күләмнән артып китә».

- 2.8.2.1 пунктының 3 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, моңа ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган граждан мондый гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар керми, федераль законнар нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алу хокукы булган ширкәт, Россия Федерациясе субъектлары законнары белән яки әлеге Кодексның 39_18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык кишәрлеге булса), шулай ук гражданнар бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә үз ихтыяҗлары өчен урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);»

2. Әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Милек һәм җир мөнәсәбәтләре
палатасы рәисе Н. В. Попкова